| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| «30» апрель 2019 ел. | №102 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә һәм Балтач муниципаль районы прокуратурасының 2019 елның 20 феврале 02-01-22-2019 номерлы мәгълүмати хаты, 2019 елның 15 апрелендә үткән халык тыңлаулары һәм Балтач муниципаль районының «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 декабрендәге 94 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 2.25 пунктта «киңлек» сүзе алдыннан “гомуми файдалану" дигән сүзтезмә өстәргә;

1.2. Кагыйдәләрне 2.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"2.2.Төзекләндерү элементлары- декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.»

1.3. 3.1 пунктта «Вакытлы корылмалар» дигән сүзтезмәләрдән соң, территорияне чүп үлән һәм куак үсемлекләре, барыннан да элек, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы үсемлекләр (шул исәптән Сосновский борщевигы) сүзтезмәсе белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат http:/pravo.tatarstan.ru/ порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3.Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Балтач муниципаль районы
Смәел авыл җирлеге башлыгы: Р.Г.Йосыпов